**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеге турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы 4 кисәге 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфаларын биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һөнәри хезмәт эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфаларының кушымтада бирелүче исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына 30 көн эчендә түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Реестрының 3 кисәгендәге 1 бүлеге нигезендә баш вазыйфалар төркеменә караучы барлык вазыйфаларны кертеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфаларның исемлеген;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан

вазыйфага билгеләп куелучы һәм вазыйфадан азат ителүче «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфаларның исемлеген.

3. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары булмаган дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясендәге вазыйфаларны биләүче Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен эшкә алучылар вәкилләренә аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы кайбер вазыйфаларының исемлеген раслауны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан,Кремль
2017 ел, 06 октябрь
№ ПУ-889

Татарстан Республикасы
Президентының
2017 елның «06» октябрендәге
ПУ-889 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең Татарстан Республикасы дәүләт органнарында аларны биләү билгеле бер срокка төзелгән хезмәт контрактлары шартларында тормышка ашырылучы «җитәкчеләр» категориясендәге кайбер вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәчесе.
2. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы.
3. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе.
4. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Эксперт департаменты җитәкчесе.
5. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе секретариаты җитәкчесе.
6. Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы.
7. Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт протоколы идарәсе башлыгы.
8. Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы.
9. Татарстан Республикасы Президентының Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү идарәсе башлыгы.
10. Татарстан Республикасы Президентының Документлар белән тәэмин итү һәм контроль идарәсе башлыгы.
11. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе.
12. Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты директоры.
13. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре.
14. Татарстан Республикасы Президентының Матбугат хезмәте җитәкчесе.

15. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының дәүләт бүләкләре бүлеге мөдире.

16. Татарстан Республикасы Президенты Аппаратының махсус документаль элемтә бүлеге мөдире.

17. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире.

18. Татарстан Республикасы Куркынычсызлык Советы Секретаре эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге мөдире.

19. Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе секретариаты җитәкчесе.